Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 25-3 05.10.2021

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең шәһәр төзелеше эшчәнлегенә кагылышлы бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, « Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең шәһәр төзелеше эшчәнлегенә кагылышлы бер өлешен тапшыру турында» 2021 елның 27 сентябрендәге 12-6 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы карары, « Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2021 елның 19 июлендәге 20-1 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең түбшндәге өлешен кабул итәргә:

- җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү;;

- рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (www.spasskiy.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Галәветдинова